**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» января 2019 с. Тюлячи № 84

Теләче муниципаль районы территориясе өстендә аэронавигация мәгълүматлары документларында хәбәр бастырылмаган авиация эшләренә, парашюттан сикерүгә, һава судноларының күрсәткеч очышларына, пилотсыз очу аппаратларын очыртуга, бәйләп куелган аэростатларны күтәртүгә, Теләче муниципаль районы чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга төшүгә (очып китүгә) рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә Административ регламентка үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы Федераль законның дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрдән файдаланганда гражданнарга өстәмә гарантияләр булдыру өлешенә үзгәрешләр кертү турында»гы 2018 елның 19 июлендәге Федераль законга, 2003 елның 6 октябрендәге 131 санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 16 октябрендәге 621 санлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясе өстендә авиация эшләренә, парашюттан сикерүгә, бәйләп куелган аэростатларны күтәртүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә Административ регламентны раслау турында»гы карары белән расланган (алга таба - карар) (2018 елның 14 мартындагы 141 санлы карар редакциясендә) Теләче муниципаль районы территориясе өстендә аэронавигация мәглүматлары документларында хәбәр бастырылмаган авиация эшләренә, парашюттан сикерүгә, һава судноларының күрсәткеч очышларына, пилотсыз очу аппаратларын очыртуга, бәйләп куелган аэростатларны күтәртүгә, Теләче муниципаль районы чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга төшүгә (очып китүгә) рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә Административ регламентның Муниципаль хезмәтләр күрсәтү стандарты дигән икенче юлының 2.5 баганасына түбәндәге җөмләләрне өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүче орган гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле булган документларны башта кабул итмәгәндә, тиешле мәгълүматларның булмавы яки дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматларны таләп итәргә, яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән, түбәндәге очраклардан тыш, баш тартырга хокуклы түгел:

а) муниципаль хезмәт күрсәтүгә башта бирелгән гаризадан соң муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив-хокукый актлар таләпләре үзгәргәндә;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны башта кабул итмәгәннән соң бирелгән документларда хата, яки алдан бирелгән документлар комплектына кертелмәгән муниципаль хезмәт күрсәтү булганда;

в) документлар көченең срогы чыгу яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле булган документларны башта кабул итмәгәннән соң яки муниципаль хезмәт күрсәтүдә мәгълүматлар үзгәрү;

г) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 2010 елның 27 июлендәге 210 санлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 өлешендә күздә тоткан оешма хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны башта кабул итмәгәндә яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартканда документ белән расланган хаталы яки законга каршы гамәле (чара күрмәве) ачыкланганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның җитәкчесе, күпфункцияле үзәк җитәкчесе яки 2010 елның 27 июлендәге 210 санлы Федераль законның 16 статьсы 1.1 өлешендә күздә тоткан оешма җитәкчесе гариза бирүчегә язмача хәбәр итә, шулай ук тудырган уңайсызлыклар өчен гафу үтенә.».

2. Әлеге карарны Теләче муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольне Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы Ф.С. Вәлиевка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин